Ринат Мәннан

Ялкау өстәл



Ринат Мәннан

Ялкау өстәл

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-5
М 11

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

Рәссамы ***Илдус Әҗемов***

Мәннан Ринат

М 11 Ялкау өстәл: Шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 23 б.

ISBN 5-298-04199-X

© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Ринат Мәннан, 2005

Яшеннең шырпысы бармы?

Болытларда яшен яшьни —
Сызылып уты кала.
Кибетләр бит җирдә генә,
Шырпысын каян ала?

Кара песи

Кара песи моңсулана:
— Нигә мине сөймиләр?
Урамны чыга башласам,
«Кит моннан!» — гына диләр.

Сарылары, сорылары
Йөриләр рәхәтләнеп.
Шул ук песи икәнемне
Белермиләрме белеп?

Төсем белән ярамыйм! —
Кешеләрне аңламыйм.

Ак аю

Төньякта бер океан бар.
Исеме аның Бозлы.
Ак аю ак боз өстендә
Дөнья гизә ялгызы.

Бервакыт чумам дигәндә,
Күреп ала ул кораб.
«Абыема охшаган», — дип,
Бик озак тора карап.

«Минем кебек үзе ап-ак,
Борыны да кап-кара.
Ләкин каян төтен чыга?» —
Ак аю хәйран кала.

Юмарт болыт

Яңгыр коеп болыт китте —
Бер бөртеге калмады.
Зәңгәр күктә кояш калды —
Болыт аны алмады.

Дөбер-дөбер шартласа да,
Юмарт икән ул болыт.
Салават күпере чыккан
Төсле манзара булып.

Кызыл күбәләк

Азат ак күбәләк тотты,
Сара — сары күбәләк.
— Кызылны тотыйк! — дип, алар
Йөгерәләр бергәләп.

— Нигә сезгә мин кирәк? — дип,
Кызылы куйды сорап.
— Киптерергә сине! — диде
Азат, Сарага карап.

— Китап бите арасына
Куяр идек кыстырып...
Күбәләк карый Азатка
Һәм Сарага тутырып:

— Ә минем очасым килә
Бу чәчәкле болында!..
Ятьмә бүтән күренмәде
Азат, Сара кулында.

Нәрсә ул җил?

— Кояшны, күкне, болытны
Күреп була, — ди Җәмил, —
Ә җилне һич күреп булмый.
Нәрсә соң ул, әни, җил?

— Соравың, улым, бик җитди.
Җил — күзгә күренмәс кул!
Ботка ашамаганнарны
Этеп кенә ега ул!

Укытучы булып уйныйбыз

Безнең беренче сыйныфта
Әй шау-гөр көне буе!
Дәрес дип тә әйталмассың —
Әйтерсең бака туе.

Кул күтәрү дигән нәрсә
Төшеңә дә кермәстер.
Минем укучыларымның
Бигрәк тиктормас тел.

«А» хәрефен күрсәткәндә,
Алар миңа «Б» диләр,
«Б» хәрефенә «М-ә-ә» диләр,
Әйтерсең лә бәтиләр.

Өчне икегә куш, дисәм,
Алар миңа, бер, диләр.
Өйләрендә әниләре
Ник тәрбияләмиләр?

Менә нинди балалар.
Бала түгел, бакалар!

Нишли черки шәһәрдә?

Яшәгән, ди, зур урманда
Кечкенә генә черки.
Рәхәтләнеп яшәгән, ди,
Ирекле булган чөнки.

Куянкайның тешли икән
Авырттырып колагын.
Бүренең борыны шешкән,
Булган ул нәкъ клоун!

Беркем берни дә әйтмәгән,
Черки көннән-көн азган.
Аюларга, пошиларга
Күчкән, ди, ул бераздан.

«Боларның каны тәмле дә,
Тик болар гына бик аз...»
Ә беркөн шул зур урманда
Туктаган кызыл «КамАЗ».

«Менә моның каны күптер, —
Сөенгән черки. — Кем син?..»
Борынын тыгып караса,
Моторда... зәһәр бензин!

Борынын кая куярга
Белмәгән, ди, авырткан.
«Аннан барыбер үч алам, —
Дигән черки. — Канга-кан!»

Шуннан бирле, имеш, черки
Очып йөри шәһәрдә.
«Эзлим, эзлим
КамАЗ-з-зны!» — дип
Безелди, ди, хәзер дә.

Тун кигән акбай

Салып аттым туфлиемне,
Салдым мин күлмәгемне.
Су буена комга яттым —
Кыздыр, кояш, тәнемне!

Гәзиттән башлык ясадым,
Эссе капмас башыма.
Акбаем да рәхәтләнеп
Ятты минем каршыма.

...Ул да инде — туны аша! —
Кызынам дип маташа.

Язгы сөенеч

Бал корты оча безелдәп.
Канатлары — пыяла...
Һәр чәчәккә куныл гүя
Хәлләрен белеп ала.

Аның язгы сөенечен
Чикли алмый бер киртә.
Бөтен-бөтен чәчәкләргә
Тели:
— Хәерле иртә!

Җиләк җыйганда

Иртә белән Кыям йөри
Җиләк җыеп бакчада.
Берсен чиләккә сала ул,
Берсен авызга каба.

— Нигә җиләгең аз? — диеп
Карый Зилә Кыямга.
— Берьюлы ике эш эшлим:
Ашыймын да, җыям да!

Төклетура

Ай-яй-яй зур төклетура
Оча минем янымда.
Кызынырга килгән идем,
Кызынып булмас монда.

Күлмәгемне киим тизрәк,
Төклетура чакканчы.
Өйдә китап укырмын мин,
Монда куркып ятканчы.

Сикереп тордым. Калдырма, дип
Әйтә гүя курчак та.
Төклетура, талга куныр,
Әйтте миңа шул чакта:

«Бераүне дә мин бит чакмыйм —
Һәрчак матур уй корам.
Ак күлмәгең бигрәк матур —
Чәчәк мәллә дип торам».

Яратмыйм...

Яратам «Икмәк» кибетен.
Анда матур апалар
Йомшак ипи, сохарилар,
Ап-ак күмәч саталар.

Яратам мин «Сөт» кибетен.
Анда матур апалар
Сөт, катык, татлы эремчек,
Тәмле каймак саталар.

Яратам «Конфет» кибетен.
Анда матур апалар
Прәннек, зефир, шоколад һәм
Татлы конфет саталар.

Яратмыйм «Аучы» кибетен.
Анда шундый апалар —
Бүре, куян тоту өчен
Тимер капкан саталар!

Җәмил саный

— Бер — салкын,
Ике — җил,
Өч — кар, —
Ди Җәмил.
— Дүрт — көрт...
Тиздән Кыш бабайны
Көт!

Ялкау өстәл

Мин яратам чисталыкны!
Күзгә ямь биреп тора.
Күршеләрдә көн дә күрәм —
Өстәл ялт итеп тора!

Гаҗәпләнеп карап торам:
Кашыклар, чәйнек, уклау...
Үзен-үзе җыештырмый —
Өстәлебез бик ялкау!

Өйдә калгач...

Илнур радио тынлый,
Әтисе киткәч чыгып.
Шөрепләрен борып алган —
Эчен карый тырышып.

Кай җирендә сөйләшәләр?
Җырлый радио ничек?..
Шул чагында бүлмәсенә
Ачылып китә ишек.

— Әй, улым, ник радионы
Ваттың? — ди әти-әни.
— Мин эзләдем артистларны!..
Анда алар күренми...

Барсын узып киткәнмен

Иртәгесе көннән башлап
Йөгерә башлыйм иртән.
Йөрәкләргә, мускулларга
Ул бик файдалы икән.

Аны бүген безгә әйтте
Дәрестә укытучы.
— Будильнигыбызны, әни,
Сәгать алтыга куйчы!

...И йөгерәм рәхәтләнеп,
Барсын узып киткәнмен...
Хыялны төштә күргәнмен,
Йоклап киткән икәнмен.

Үгезгә киңәш

Ун, тугыз, сигез —
Әй, симез үгез.

Җиде, алты, биш —
Бүре килә ич!

Дүрт, өч, ике, бер —
Тиз качып өлгер!
Йөз, туксан, сиксән —
Калырсың исән.

Җитмеш, алтмыш, илле —
Җәтрәк кач инде.

Кырык, утыз, егерме —
Әйтмәдең, димә, яме?!

Ун —
Абзарында кун!

Минем этем

Кояш күктә. Көне кызу.
Хәл калмады чыдарлык.
Иртүк минем Актүш йөри,
Кызыл телен чыгарып.
Ничек көн кызулана —
Шулай тел... озыная!

Алдакчы Вафа

«Укытучы авыр сорау
Бирсә, мин кызык итәм:
«Минем эчем авырта», — дип,
Дәрестән сорап китәм.

Сөйләр әле белгән кеше,
Ә миңа ник «икеле»?
Минем алар болай да күп,
Көндәлектә, билгеле».

...Шулай итеп язлар җитте,
Алдашып чыга-чыга.
Вафа алтынчы сыйныфта
Калды икенче елга.

Хәйләкәр керпе

Гадилә әйтә керпегә:
— Белдем синең сереңне!
Син соң элек Миләүшәдә
Кактус түгел идеңме?

8 Март түгел!

Шыплап тулган трамвайда
Мәктәптән кайтам кичен.
Иң беренче булып кердем
Утырып барыр өчен.

Трамвай йөртүче боера —
Белмим аны кем тыңлар?! —
Имеш, торып хатыннарга
Бирегез, ди, урыннар.

Торды микән берсе, белмим.
Күзем йомык иде гел.
Нигә торыйм ди, бүген бит
Сигезенче Март түгел...

Чистартам

Тузаннарны мин суыртам
Тузансуырткыч белән.
ИДәннәр ялтырап тора,
Чип-чиста була келәм.

Чалбарларым да чистарды,
Чистарды бүрегем дә.
Әти-әни эштә әле —
Мин бит үз ирегемдә.

Пианино да чистарды,
Диван да булды чиста.
Озынборыннарга кадәр
Суыртып алдым хәтта.

Ә көндәлектә «ике»ләр...
Тора җанны суытып.
Күпме генә тырышсам да,
Булмый һич тә суыртып...



Кызыл «икеле»

Белгәнемчә, «икеле»ләр
Йә зәңгәр төстә була,
Йә кызыл төстә була.
Көндәлегеңә куна!

Кызылы сиңа эләксә,
Вәт чыгара ачуны!
Чөнки укытучының да
Анда кергән... ачуы.

Әй котсыз да «икеле» —
Бөкре шайтан шикелле!



Шпаргалка

Ә шпаргалка барын белә
«Бишле»гә ким дигәндә.
Ул миңа яхшы булыша,
Имтиханнар биргәндә.

Беркөн галим радиодан
Мактады шпаргалканы:
«Файдага була язсалар
Малайлар-кызлар аны».

Ләкин мин соңгы сүзләрен
Бер дә итмәдем кабул.
«Тик имтиханга барганда
Өйдә калсын!» — диде ул.

Гаепсез укучы

Гел «икеле» аласың, дип
Орыша әни.
Күп «икеле» алганга мин
Гаеплемени?

Кем беренче булып чыга
Алга — тактага?
Ә кемнең фамилиясе
Башлана «А»га?

Мине инде газаплыйлар
Ничә ел менә!
Их, әлифба ник башланмый
«Я» хәрефенә?!

Кем эше?

Трамвай тәрәзәсенә
Язылган «Дания» дип,
Утыргычка «Миләүшә» дип,
Тоткычка «Сания» дип.

— Бу тәртипсез кызлар эше! —
Дип йөрмәгез ялгышып.
Белмәсәгез, белегез, бу —
Гашыйк малайлар эше.

Сөйләшмәгәч...

Көлмәгез әле, кызлар, сез,
Бик күп сөйли, дип, миннән.
Әнә балык! — Сөйләшмәгәч,
Мәхрүм калган теленнән.

ЭЧТӘЛЕК

Яшеннең шырпысы бармы?
... 3 ...
Кара песи
... 3 ...
Ак аю
... 5 ...
Юмарт болыт
... 5 ...
Кызыл күбәләк
... 6 ...
Нәрсә ул җил?
... 7 ...
Укытучы булып уйныйбыз
... 8 ...
Нишли черки шәһәрдә?
... 9 ...
Тун кигән акбай
... 10 ...
Язгы сөенеч
... 10 ...
Җиләк җыйганда
... 11 ...
Төклетура
... 11 ...
Яратмыйм...
... 14 ...
Җәмил саный
... 14 ...

Ялкау өстәл
... 15 ...
Өйдә калгач...
... 15 ...
Барсын узып киткәнмен
... 16 ...
Үгезгә киңәш
... 16 ...
Минем этем
... 17 ...
Алдакчы Вафа
... 17 ...
Хәйләкәр керпе
... 17 ...
8 Март түгел!
... 18 ...
Чистартам
... 18 ...
Кызыл «икеле»
... 19 ...
Гаепсез укучы
... 20 ...
Шпаргалка
... 20 ...
Кем эше?
... 21 ...
Сөйләшмәгәч...
... 21 ...

Литературно-художественное издание для детей

Ринат Маннан
(Архипов Ринат Николаевич)

Ленивый стол

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Т.В.Гредюшко*
Корректоры *Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 21.10.2005. Форматы 70×100 $^1/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Korinna» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 1,95 . Шартлы буяу-оттиск 3,25.
Нәшер-хисап табагы 3,37 . Тиражы 5000 д. Заказ А-795.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
ГУП Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/ E-mail: tki@books.kazan.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

ААЖ «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.